**Важашур авыл җирлеге башкарма комитеты**

**Карар**

**27 февраль 2023 ел** **№16**

Важашур авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 октябрендәге 394-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Важашур авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрындагы 5 номерлы карарына (2022 елның 24 октябрендэгы 11 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырыла:

«- медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке эшләр органнарына (полиция) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда булышлык күрсәтү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе П.Л.Иванов